**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«23» 11 2021 ел Яр Чаллы № 4232

Круглое Поле авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча документларны эшли башлау турында

Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетының гаризасын карап, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 июлендәге 44/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча документларны эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары нигезендә техник регламентлар таләпләренә таянып алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин